**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Масягут овского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Дружба д. 12, село Масягут ово,
Азнакаевского муниципального района, 423321
Тел. (факс) (88-55-92) 38-2-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Мэсгут авылы җирлеге башкарма комитеты**

Дружба урамы , 12, Мэсгут авылы
Азнакай муниципаль районы, 423321
Тел. (факс) (88-55--92) 38-2-16

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» октябрь 2016 ел №14

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6, 27, 50 статьялары һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалануның кушымтада бирелә торган кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Э.А.Габдрахманов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2016 елның 27 октябрендәге 14 номерлы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләре**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсәгут авыл җирлеге территориясендә муниципаль һәм дәүләт милкендә булган җирләрдә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү рекреацион зоналарын булдыру һәм файдалану кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) Россия Федерациясенең Су кодексының 6 нчы, 27 нче, 50 нче маддәләре һәм Татарстан Республикасының 28.07.2004 №45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 15 нче статья таләпләрен исәпкә алып эшләнгән.

1 нче статья. Куллану өлкәсе

1.1. Кагыйдәләр Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милкендәге җирләрдә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү рекреацион зоналарын булдыру һәм куллану өчен билгеләнгән, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар, гражданнар тарафыннан кулланыла.

1.2. Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланa.

1.3. Кагыйдәләр гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында җиһазландырылган рекреацион ял зоналарын булдыру һәм куллану тәртибен билгели һәм үтәлергә тиеш.

2. статья. Төп төшенчәләр һәм терминнар

**Су объекты-**табигый яисә ясалма сулык, су агымы, йә суларының даими яисә вакытлыча тупланышы су режимының характерлы формаларына һәм билгеләренә ия булган башка объект;

**Гомуми файдаланудагы су объектлары** – дәүләт яки муниципаль милектә булган, Россия Федерациясенең Су кодексы белән башкача каралмаган очракта, гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен бушлай файдалану мөмкинлеге булган өске су объектлары;

**Су саклау зонасы** – диңгезләр, елгалар, чишмәләр, каналлар, күлләр, сусаклагычларның яр буе сызыгына (су объекты чикләренә) якын урнашкан территория, анда күрсәтелгән су объектларын пычрату, чүпләү, ләмләнүне һәм аларның су ресурсларының кимүен булдырмау, шулай ук су биологик ресурслары һәм башка хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы яшәү мохитен саклау максатында махсус режим билгеләнә.

**Яр буе зонасы** – су саклау зоналары чикләрендә урнашкан, диңгезләр, елгалар, инешләр, каналлар, күлләр, сусаклагычлар яр буе сызыгына якынлашкан территория, анда хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә өстәмә чикләүләр кертелә;

**Яр буе зонасы** – гомуми файдаланудагы су объектының яр буе сызыгы (су объекты чикләре) буйлап урнашкан җир полосасы (яр буе зонасы), гомуми

файдалану өчен билгеләнгән. Гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе зонасы киңлеге егерме метр тәшкил итә, каналларның, шулай ук башыннан авызына кадәр озынлыгы ун километрдан артмаган елгалар һәм инешләрнең яр буе зонасыннан тыш. Каналларның, шулай ук башыннан авызына кадәр озынлыгы ун километрдан артмаган елгалар һәм инешләрнең яр буе зонасы киңлеге биш метр тәшкил итә;

**Рекреацион ял зонасы** – гомуми файдаланудагы су объектының су саклау зонасы чикләрендә, муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан һәм рекреацион максатларда файдалану өчен җиһазландырылган территория;

**Рекреацион ял зонасын куллану** – рекреацион (ял, туризм, спорт) һәм коену максатларын канәгатьләндерү өчен рекреацион ял зонасын төрле ысуллар белән куллану;

**Кулланучылар – баланс тотучылар** - муниципаль берәмлек администрациясе тарафыннан билгеләнгән рекреацион ял зоналарының эшләве өчен җаваплы затлар;

**Рекреация билгеләнешендәге җирләр –** гражданнарның ял итү, туризм, физик культура һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен билгеләнгән һәм кулланылган җирләр. Рекреация билгеләнешендәге җирләр составына ял йортлары, пансионатлар, кемпинглар, физик культура һәм спорт объектлары, туристик базалар, стационар һәм палаткалы туристик-сауыктыру лагерьлары, балыкчы һәм аулаучы йортлары, балалар туристик станцияләре, туристик парклар, уку-туристик сукмаклар, трассалар, балалар һәм спорт лагерьлары, пляжлар һәм башка шундый объектлар керә.

Уку-туристик сукмаклар һәм трассаларны җир участоклары хуҗалары, җир кулланучылар, җир ияләре һәм җир участоклары арендачылары белән килешү нигезендә куллану сервитутлар нигезендә башкарылырга мөмкин; шул ук вакытта әлеге җир участоклары кулланудан алынмый.

**Рекреация билгеләнешендәге җирләрдә аларның максатчан билгеләнешенә туры килмәгән эшчәнлек тыела.**

3 статья. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

3.1. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- муниципаль берәмлек чикләрендә Кагыйдәләр эшләү һәм раслау;
- гамәлдәге законнарга туры китереп, кызыксынган дәүләт башкарма хакимият органнары белән килешеп, рекреация зонасы участокларын билгеләү;
- рекреация зонасы белән идарә итү, файдалану, карау.
- ял зоналарын территорияне планлаштыру схемаларына, җир куллану һәм авыл җирлегендә төзелеш кагыйдәләренә кертү;
- җирле үзидарә органнары белән килешеп, тиз йөрешле ял көймәләре һәм спорт катерлары өчен су объектларында спорт зоналары урнаштыру урыннарын билгеләү;
- рекреацион зона эксплуатациясе һәм тоту өчен җаваплы кулланучыны билгеләү;
- гомуми файдаланудагы су объектларында рекреацион ял зоналарын куллануны чикләү турында мәгълүмат бирү: массакүләм мәгълүмат чаралары (басма басмалар, радио, телевидение, интернет) аша, су объектлары ярлары буйлап урнаштырылган махсус мәгълүмат билгеләре ярдәмендә;
- рекреацион ял зоналарына суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аның нәтиҗәләрен бетерү чараларын гамәлгә ашыру;
- муниципаль милектә булган рекреацион ял зоналарын саклау чараларын гамәлгә ашыру.

3.2. Гомуми файдаланудагы су объектларын куллану, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган, су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләренә туры китереп башкарыла.

3.3. Кагыйдәләр муниципаль берәмлекнең рекреацион ял зоналарына кагыла, алар территориясендә рекреацион максатларда куллану өчен яраклы су объектлары бар.

4 нче статья. Рекреацион ял зоналарының юридик статусы, аларны оештыруның оештыру-хокукый формалары, милекне куллану тәртибе

4.1. Ял зоналары урнашкан җир участоклары федераль, региональ яки муниципаль милек булып тора.

4.2. Муниципаль берәмлек чикләрендә ял зоналары булдыру өчен җир участоклары бирү гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.

4.3. Ял зоналарының эшләве өчен җаваплы булган кулланучылар - баланс тотучылар, аларга ял зонасы инфраструктурасы белән җир участоклары беркетелә.

4.4. Ял зоналары участоклары һәм аларга якын су объектлары белән файдалану, җир куллану хокукын раслаучы документлар һәм закон нигезендә рәсмиләштерелгән су куллану килешүе буенча, ял зоналары баланс тотучылары тарафыннан башкарыла. Әлеге документларда шәһәр төзелеше режимнарын, табигатьтән файдалануны һәм әйләнә-тирә мохитне саклау таләпләре күрсәтелергә тиеш.

4.5. Ял зоналары баланс тотучылары булып гамәлдәге законнар һәм милек мөнәсәбәтләрен көйләүче муниципаль норматив актларны үтәгәндә, предприятиеләр һәм оешмалар, шулай ук башка кулланучылар - баланс тотучылар булырга мөмкин.

4.6. Кулланучылар - ял зоналары җир участоклары баланс тотучылары, арендаторның ризалыгы белән, җир участокларын субарендага бирә алалар, законнар һәм башка норматив актлар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда. Кулланучылар - ял зоналары җир участоклары баланс тотучылары, субарендаторлар ял зонасы җирләрен максатчан файдалану, милекне саклау һәм ял зонасы режимын тәэмин итү өчен җаваплылык тоталар.

4.7. Кулланучылар - баланс тотучылар ял зоналары территориясендә урнашкан биналар, корылмалар һәм башка милек белән идарә итәләр, елга гидрокорылмалары - плотиналар, буалар, су агызу корылмалары, су агызу коллекторлары, яңгыр кабул итү һәм күзәтү коелары, үткәргеч торбалар һ.б.дан тыш.

Кулланучы - баланс тотучы милек хуҗасының ризалыгы белән биналар, корылмалар һәм башка милекне, территория һәм ял зонасы су объектын файдалану хокукларын тапшыру белән бергә, законнар белән билгеләнгән тәртиптә арендага бирә ала.

5 нче статья. Ял зоналарын оештыру, реконструкцияләү һәм бетерү

5.1. Кагыйдәләр гамәлгә кергән вакытта булган ял зоналары оештыруга мохтаҗ. Бу вакытта нигезләмә төзелә һәм документлар пакеты әзерләнә, алар үз эченә ала:

- җиргә хокукларны рәсмиләштерү һәм су куллану килешүләре;
- территорияне төзү һәм төзекләндерү проекты;
- юридик затларның устав документлары – кулланучылар - баланс тотучылар;
- сулыкта су сыйфатын тикшерү үткәрү.

5.2. Ял итү рекреацион зонасы махсус компетентлы комиссия тарафыннан эксплуатациягә кабул ителә, комиссия составы муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

Комиссия составына Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе вәкилләре, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль идарәсе, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы вәкилләре кертелә. Эксплуатациягә кабул итү нәтиҗәсендә ял итү зонасының юридик статусы һәм аның төре билгеләнә, ул хәзерге хәлгә һәм киләчәктә үсеш һәм җиһазландыруны исәпкә алып туры килә.

5.3. Әгәр дә ял итү зонасының хәле тикшерү нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек түгел дип табылса, аның табигатьне саклау реконструкциясе үткәрелә. Реконструкция махсус төзелгән проект буенча башкарыла, башлангыч - рөхсәт документлары булганда. Проект билгеләнгән тәртиптә килештерелергә һәм муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан расланырга тиеш.

5.4. Муниципаль берәмлекнең яңа ял итү рекреацион зоналарын булдыру Татарстан Республикасы Роспотребнадзор идарәсе, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль идарәсе, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән килешеп, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла.

Карар белән билгеле бер территориянең рекреацион ял зонасы буларак куллану мөмкинлеге һәм яраклылыгы билгеләнә. Яңадан булдырылган һәр рекреацион ял зонасына башлангыч - рөхсәт документациясе, ял зонасын оештыру (реконструкцияләү) проекты рәсмиләштерелергә тиеш, алар нигезендә табигатьтән файдалану шартлары һәм режимнары билгеләнә (планлаштыру эшләрен башкару мөмкинлеге, рөхсәт ителгән рекреацион йөкләнеш, территориянең функциональ зоналаштыруы, вакытлы һәм капиталь корылмалар төзү мөмкинлеге, эчәр су белән тәэмин итү һәм канализацияләү шартлары, автостоянкалар оештыру һ.б.) һәм гамәлдәге муниципаль норматив актларга туры килгән башка документация таләп ителә. Тик килешенгән һәм расланган проект документациясе булган очракта гына ял зонасын файдалану хокукын башка юридик затларга тапшыру шартлары билгеләнергә мөмкин, алар билгеләнгән табигатьтән файдалану шартларын үзгәртү хокукыннан башка үтәргә тиеш.

5.5. Яңа ял итү рекреацион зоналарын булдыру функциональ, төзелеш һәм ландшафт зоналаштыру таләпләренә, районның табигый комплексын саклау һәм үстерү перспектив планнарына туры китереп башкарылырга тиеш.

5.6. Ял итү рекреацион зонасын бетерү санитар-эпидемиологик, экологик һәм техник күзәтү органнарының тиешле нәтиҗәләре һәм тикшерү актлары нигезендә башкарылырга тиеш. Ял итү зонасын бетерү нигезе булып, зонада канәгатьләнерлек санитар-экологик хәлне тәэмин итү мөмкин булмау яки ял итү зонасы территориясен башка максатларда куллану турында кабул ителгән карар тора.

## 6 нчы статья. Эксплуатацияләүче оешманы билгеләү, җаваплылык һәм эксплуатация чараларын гамәлгә ашырганда буйсыну.

6.1. Ял итү рекреацион зонасын эксплуатацияләү тиешле бүлекчә, милекче яки аренда хокукы нигезендә рекреацион зонадан файдаланучы юридик зат тарафыннан башкарыла.

6.2. Ял итү рекреацион зонасының торышы өчен җаваплы булып кулланучы - баланс тотучы, шулай ук ял итү зонасын эксплуатацияләүче оешма тора, бу эксплуатацияләүче бүлекчә турындагы нигезләмә яки ял итү зонасын арендага (эксплуатациягә) алу турындагы килешү белән билгеләнә.

6.3. Су акваториясен чистарту белән пляж зоналарын эксплуатацияләүгә кагылышлы өлештә рекреацион зоналар кулланучылары муниципаль берәмлекнең Башкарма комитетына оператив буйсынуда тора.

6.4. Мәҗбүри чаралардан тыш, ял зонасының эшләве һәм ял итүчеләргә хезмәт күрсәтү белән бәйле эксплуатация чаралары санитар-экологик иминлек, төзекләндерү һәм ял зонасының куркынычсызлык дәрәҗәсен нормативларга туры

китереп тәэмин итү эшләрен дә үз эченә алырга тиеш. Алар даими һәм бер тапкырлык булырга мөмкин, мәсәлән, җәйге сезон ачылышына багышланган.

6.5. Ял зонасының кулланучы-баланс тотучысы ел саен рекреацион ял зонасы чикләрендә гомуми файдаланудагы яр буйларын, төбен, су акваториясен, пляжны чистарту эшләрен оештыра, мондый эшләрне лицензияле оешмалар белән килешү нигезендә башкара.

6.6. Әгәр су объекты тулысынча ял зонасы территориясендә урнашкан булса, аның эксплуатациясе ял зонасының кулланучы-баланс тотучысы тарафыннан башкарыла. Су объекты эксплуатациясе чыгымнары рекреацион ял зонасы эксплуатациясе чыгымнары составында каралырга тиеш.

## 7 статья. Ял зоналарын урнаштыру, рекреацион файдалану һәм төзекләндерү дәрәҗәсенә таләпләр

7.1. Территорияне рекреацион ял зоналарын урнаштыру өчен файдалану мөмкинлеге норматив-хокукый актларга туры китереп, әлеге территория өчен билгеләнгән көйләү режимы белән билгеләнә.

Ял зоналарын урнаштыру өчен территорияләрне куллану, аларның чикле сыйдырышлыгын рөхсәт ителгән рекреацион йөкләнешләрне исәпкә алып билгеләү, рекреацион куллану төрләре һәм төзекләндерү дәрәҗәсе һәр конкрет очракта проектлау биремнәрен һәм ял зоналарын эксплуатацияләү кагыйдәләрен мәҗбүри килештерү юлы белән хәл ителергә тиеш.

7.2. Ял зоналарында түбәндәге рекреацион куллану төрләре рөхсәт ителә: коену, йөзү чараларында йөрү, су спорты, моржлау, спорт уеннары, чаңгы һәм тимераякта шуулар, ат спорты һәм аттракционнар. Ял зоналарын ел әйләнәсендә күпмаксатлы куллану өстенлекле. Рекреацион куллану юнәлешләре ял зонасы төренә, табигый комплекс территориясе категориясенә, су объекты төренә, табигый шартларга һ.б. бәйле, ял зонасын оештыру вакытында билгеләнә.

7.3. Рекреацион куллану төрен билгеләгәндә, норматив документларга туры китереп билгеләнгән табигый объектка рөхсәт ителгән рекреацион йөкләнештән чыгып эш итәләр.

7.4. Коену мөмкинлеге булган эксплуатациягә кабул ителгән рекреацион ял зоналары аерым бинада урнаштырылган медицина пункты белән җиһазландырылырга тиеш. Ял зонасы баланс тотучы кулланучы ашыгыч медицина ярдәме машиналарының ял зонасы территориясенә иркен керүен һәм хәрәкәтен тәэмин итәргә тиеш.

## 8 статья. Ял зоналарының санитар-экологик торышына һәм инженер җиһазландыруына таләпләр

8.1. Ял итү зоналары өчен территорияне куллану проект материаллары белән билгеләнә, әйләнә-тирә мохиткә йогынты бәяләнә һәм ял итү зонасы территориясендә ландшафтның табигый өлешен саклау һәм торгызу чаралары тәкъдим ителә.

8.2. Ял итү зонасы территориясе инженер җиһазландыруга ия булырга тиеш, ул түбәндәгеләрне үз эченә ала: өслек агымын җыю һәм агызуны оештыру (су агызу, үткәргеч торбалар, дренажлар, шуышуны булдырмау корылмалары), пычранган өслек агымының су объектына эләгүен булдырмау; су белән тәэмин итү һәм су агызу. Инженер әзерлек чаралары гамәлдәге норматив документларга туры килгән проект белән билгеләнә.

8.3. Экологик реабилитация максатында һәм яр буе полосасының су саклау функцияләрен тәэмин итү өчен түбәндәге таләпләрне үтәү кирәк: үлән капламын, агач-куакларны һәм яр буе үсемлекләрен максималь саклау, үсемлекләр белән капланмаган территория мәйданы ял зонасының гомуми мәйданының 20% тан

артмаска тиеш; үлән капламын тапталудан саклау өчен җәяүлеләр юллары челтәре рациональ планлаштырылырга һәм үтәли капламга ия булырга тиеш; ял зоналарын яшелләндерү ландшафт һәм су саклау функцияләрен үтәргә тиеш; яшелләндерү су ятмалары ярларында (яр ныгыту поясы), үзәннәр һәм чокырлар битләрендә (бит су тоткарлау поясы - илофильтрлар), шуышу һәм эрозиягә бирешкән битләрдә, чокырлар һәм үзәннәрдә үткәрелергә һәм сакланырга тиеш; учак ягу бары тик махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган мәйданчыкларда гына рөхсәт ителә; рекреация зонасы территориясендә этләр йөртү катгый тыела.

8.4. Рекреация зонасы территориясендә пычратучы матдәләр һәм каты көнкүреш калдыклары җыелу рөхсәт ителми. Калдыкларны чыгару вакытында махсуслашкан, әлеге эшчәнлек төренә лицензиясе булган оешмалар тарафыннан, килешү нигезендә, санкцияләнгән урынга (ТБО полигоны) башкарылырга тиеш. Эксплуатацияләүче оешманың штат расписаниесендә рекреация зонасы территориясен җыештыру өчен персонал каралырга тиеш.

8.5 Су буйлары (уртача күпьеллык су чигеннән 20 метр) гражданнар өчен гомуми керү мөмкинлегендә булырга тиеш.

9. статья. Су объектларының су сыйфатына таләпләр

9.1. Ял зоналарының су сыйфаты һәм су объектларының торышы гамәлдәге санитар нормалар һәм кагыйдәләр, шулай ук дәүләт стандартлары белән билгеләнә, аларның рекреацион куллану төренә карап.

9.2. Су объекты рекреацион ял зонасына коену урыны буларак кертелә, әгәр дә күпьеллык кисемтәдә (уртача) коену сезонының 70% вакытында су сыйфаты буенча коену өчен яраклы булса.

9.3. Су объектларын коену урыны сыйфатында тикшергәндә, алардагы су сыйфаты СанПиН №4630-88 «Өслек су объектларын пычранудан саклау санитар кагыйдәләре һәм нормалары» нигезендә бәяләнә. Тикшерүгә коену сезоны алдыннан яки вакытында кимендә 1 ай дәвамында контроль күрсәткечләрне үлчәү чоры алдан булырга тиеш.

9.4. Су объектының рекреацион куллану характеры турында карар, коену урыны таләпләрен тәэмин итү мөмкин булмаганда, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең территориаль хезмәте белән килешеп, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

9.5. Су сыйфатының микробиологик пычрану буенча норматив күрсәткечләрне арттыруы, су сыйфаты начарлану сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү чорында, су объектын коену өчен куллануны мөмкинсез итә.

10 статья. Ял итүчеләрнең сакланышын һәм иминлеген тәэмин итү таләпләре

10.1. Ял итү рекреацион зоналарын куллану иминлеге таләпләре түбәндәгеләрдән тора: су объектларын куллану иминлеге таләпләре (коену, көймәдә йөрү, тимераякта, чаңгыда йөрү, балык тоту һ.б.); су объектларындагы гидротехник корылмаларның торышына бәйле иминлек таләпләре; ял итү зонасы территориясендә иминлек таләпләре (янгын иминлеге, төзелеш конструкцияләренең ышанычлылыгы, куркыныч геологик процесслар булмау һ.б.).

11 статья Ял итү рекреацион зонасын санитар-экологик торышын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итүне контрольдә тоту

11.1. Ел саен җәйге сезонга әзерлек вакытында муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән комиссия тарафыннан ял итү рекреацион зонасын кабул итү үткәрелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, ял итү зонасының җәйге сезонга әзерлеген раслаучы акт төзелә. Бозулар ачыкланган

очракта, тиешле эксплуатация чараларын үткәрү таләпләре (агымдагы ремонтны да кертеп) куела, тиешле күрсәтмәләр төзелә һәм аларның күчермәләре муниципаль берәмлекнең Башкарма комитетына җибәрелә.

11.2. Коену сулыкларындагы суның сыйфаты санитар-эпидемиологик хезмәт тарафыннан контрольдә тотыла. Контроль коену сезоны башланганчы бер ай алдан һәм сезон вакытында оештырылырга тиеш.

11.3. Пробалар алу ешлыгы коену сезоны вакытында айга кимендә 2 тапкыр билгеләнә.

11.4. Сәламәтләндерү чаралары үткәрү яки пляжны ябу кирәклеген хәл итү өчен эчәк төркеме патоген бактерияләр яки энтеровируслар булуны тикшерү өчен пробалар тикшерелә.

11.5. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең территориаль органы, Татарстан Республикасы буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының төп идарәсе карамагындагы кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе органы тарафыннан бирелгән рөхсәтсез пляжны ачу һәм файдалану тыела.

11.6. Ял итү зонасының баланс тотучысы булган кулланучы коену сезоны башланганчы, Татарстан Республикасы буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе территориаль органы тарафыннан пляжның еллык техник тикшерүен үткәрергә тиеш.

## 12 статья. Эксплуатация чыгымнарын финанслау ял итү рекреация зоналары

12.1. Ял зоналарын эксплуатацияләү чыгымнарын, шулай ук милек яки башка хокук нигезендә булган табигатьне саклау реконструкциясен финанслау, муниципаль берәмлек бюджетының тышкы төзекләндерү объектларын тотуга каралган һәм чикләнгән чаралар хисабына башкарыла. Ведомстволар һәм башка оешмалар балансында булган ял зоналарын төзекләндерү чыгымнары муниципаль берәмлек бюджеты хисабына финансланмый.

## 13 статья. Ял итү зоналарын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану тәртибе.

13.1. Гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында ял итү зоналарын куллану өчен су ресурсларын куллану килешүе төзү яки су объектын файдалануга бирү турында карар кабул итү таләп ителми.

13.2. Гомуми файдаланудагы су объектларын кулланганда гражданнарның хокуклары бар:

- махсус билгеләнгән урыннарда коену һәм күпләп ял итү, туризм, спорт, һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы белән шөгыльләнү өчен су биологик ресурслары турындагы законнарга туры китереп файдалану;

- гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйларын йөрү һәм алар янында булу өчен, шул исәптән һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы белән шөгыльләнү һәм йөзү чараларын туктату өчен куллану;

- йөзү чараларында, шул исәптән кечкенә судноларда, су мотоциклларында һәм гражданнарның шәхси милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен кулланылмаган башка техник чараларда йөзү;

- гомуми файдаланудагы су объектларына керү, аларның су саклау зонасында урнашкан ял итү зоналарын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен бушлай куллану, әгәр дә законнарда башкача каралмаган булса;

- гомуми файдаланудагы су объектларының торышы турында аларны куллану өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә алу.

13.3. Ял итү зоналарын кулланганда **тыела:**

- җиһазландырылмаган урыннарда коену һәм сулыктагы суның сыйфаты билгеләнгән нормаларга туры килмәгән очракта;

- коену өчен билгеләнгән акваториядә йөзү чараларының хәрәкәте;

- башка кешеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу;

- әйләнә-тирә мохиткә зыян китерү (рөхсәтсез чүплекләр, учаклар оештыру, транспортның оештырылмаган хәрәкәте белән туфракның уңдырышлы катламын бозу, агач һәм куак үсемлекләрен бозу, зарарлау яки юк итү һ.б.).

14 статья. Әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылык.

14.1. Әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен юридик һәм физик затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм башка җаваплылыкка тартыла.

14.2. Кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылыкка тарту гаепле затларны бозуларны бетерүдән азат итми.